СОВЕТ ШУБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

«24» июнь 2025 ел

**КАРАР**

№ 136

**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 7 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны 2025 елның 28 июненнән дә соңга калмыйча «ХЕЗМӘТ» басма-редакция газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шубан авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе С.З.Васильева